Кушымта

Салават күпере

Кадерле дускай!
Кушымтаны куш битләргә аер, аларның кисәсән кис, бөклисен бөклә. Бу эштә сиңа өлкәннәр ярдәм итәр.

СЫБЫЗГЫ







Сандугач идән юа

Әтәчләрем суга бара,
Тавыкларым кер уа.
Үзем кортлар чүпләп йөрим,
Сандугач идән юа.

Соловей мне моет пол

Куры прачки у меня,
За водой петух пошел.
Сам пока ловлю жуков,
Соловей мне моет пол.

Ялкау әтәч

Чуар тавык суга бара,
Аягында чабата.
Шулвакытта әтәчебез
Киңәшләр биреп ята.

Ленивый петух

В желтой шали курица
Дрова несет, сутулится.
Петух семечки грызет,
Ей советы подает.



Сәләват күпере



Абдулла АЛИШ

Абдулла АЛИШ (1908-1944)

Абдулла Алиш (Габдуллаҗан Габделбари улы Алишев) 1908 елның 15 сентябрендә элекке Казан губернасының Спас өязе (хәзерге Татарстан Республикасының Спас районы) Көек авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә дөньяга килә. Аның бабасы Нурулла шул авылның мулласы булып, әтисе Габделбари, солдат хезмәтендә йөреп кайтканнан соң, ата йортында күбрәк хуҗалык эшләре белән шөгыльләнгән – иген иккән, умарта караган. Абдулланың әнисе Газизә дә авыл халкы арасында укымышлы хатын саналган, әдәбиятны бик яратып, шигырь һәм бәетләр чыгарырга һәвәс булган.

1917 елда сигез яшьлек Абдулланы әтисе үзләреннән унбиш чакрым ераклыктагы Ямбакты авылы мәдрәсәсенә илтеп бирә. Ул монда 1919 елга кадәр укый. 1919-1921 елларда Бураково авылында яңа ачылган совет мәктәбендә укуын дәвам иттерә, аннары Спас педагогия техникумы каршындагы җидееллык татар-рус мәктәбен тәмамлый (1922-1927).

1927 елның җәендә А.Алиш Казанга килә һәм Казан җир төзү техникумында укый башлый.

Җир төзү техникумын тәмамлагач, 1930 елның гыйнварыннан көзенә кадәр, А.Алиш Минзәлә кантоны җир бүлегендә мелиоратор булып эшли, аннары, 1931-1933 елларда, Казгрэс төзелешендә гидротехника буенча десятник һәм Казан шәһәре канализация төзелешендә техник хезмәтен башкара. 1934 елда яшь белгечне Казанда татарча чыга торган «Техника» журналының җаваплы секретаре итеп билгелиләр. 1937 елдан Бөек Ватан сугышы башланганга кадәр А.Алиш «Пионер каләме» (хәзерге «Ялкын») журналы редакциясендә һәм Татарстан радиокомитетында редактор булып эшли. 1937 елдан башлап, төп эшеннән аерылмыйча, Казан дәүләт педагогия институтының кичке бүлегендә укый. Бу еллар – язучының иң күп язган, әсәрләре белән үзен киң катлау укучыларына таныткан чор.

А.Алишны балаларның сөекле язучысы дәрәҗәсенә күтәргән жанр – әкиятләр. А.Алиш ике дистәдән артык әкият яза, аларны «Нечкәбил», «Әкиятләр», «Ана әкиятләре» исемнәре белән нәшер итә.

Бөек Ватан сугышы башлангач, А.Алиш 1941 елның июль аенда фронтка китә, разведчик сыйфатында Орлов өлкәсендә барган каты сугышларда катнаша. 1941 елның 12 октябрендә Брянск шәһәре янында, Десна елгасы буенда чолганышта калып, фашистлар кулына әсир төшә. Берлиндагы төрмәдә Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре белән очраша, алар белән бергә антифашистик оешмада эшли башлый.

1944 елның 25 августында 12 сәгать 12 минутта фашист палачлары Абдулла Алишны гильотинада җәзалап үтерәләр. Ләкин әдипнең гомерен үлем чикләми. Абдулла Алиш, көрәштәше Муса Җәлил кебек үк, туган халкы белән бергә киләчәккә горур атлап бара.

Абдулла Алиш 1939 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы иде.

2001 елда туган авылы Көектә А.Алишка һәйкәл салынды. Татарстан Язучылар берлеге Абдулла Алиш исемендәге әдәби бүләк булдырды. Көектә, Казанның Балалар иҗаты үзәгендә, 55 нче мәктәптә аңа багышланган музейлар эшли.

1990 елда Абдулла Алиш I дәрәҗә Ватан Сугышы ордены, ә 2005 елда «Җиңү» ордены белән бүләкләнде (үлгәннән соң).

Әнәс ХӘСӘНОВ әзерләде.

Алиш портретын Фәрит МУЛЛАХМӘТ ясады.




Бик шаян бүген бүре,
Бик наян бүген бүре,
Канатланып, очынып,
Күбәләк куып йөри...

Җүләр бүре

Татар халык әкияте




Бер көнне бүрегә тау өстендә бер Кәҗә тәкәсе очраган.




Бүре әйткән тәкәгә:

– Хәзер мин сине ашыймын, – дигән.



– Мин карт инде, ашаганда тешләрең авыртыр, – дигән Кәҗә тәкәсе.



– Син тау төбендә авызыңны ачып көтеп тор. Мин тау башыннан чабып төшәрмен дә туп-туры авызыңа кереп китәрмен, – дигән Кәҗә.



Кәҗә тәкәсе бик каты чабып төшеп, Бүрене шундый каты сөзеп җибәргән.



Бүре, башым ярылды бугай, дип тәгәрәп–тәгәрәп киткән.

Шәмаил: «Аллаһ – мәрхәмәт иясе»
«Рабби, әгъфир вәрхим,
вә əнтә хәйрү-р-рахимин».
(«Раббем, кичер һәм рәхимеңне күрсәт,
Син – иң яхшы шәфкать иясе!»)

Нәҗип НӘККАШ эше.

Сәләвәт күпере





Габдулла ТУКАЙ

Таян Аллага

Әй бәһале, әй кадерле, әй гөнаһсыз яшь бала!
Рәхмәте бик киң аның, һәрдәм таян син Аллага!

Йа Ходай, күрсәт, диген, ушбу җиһанда якты юл;
Ул – рәхимле: әткәң-әнкәңнән дә күп шәфкатьле ул!

Саф әле күңлең синең, һичбер бозык уй кермәгән,
Пакь телең дә һич яраусыз сүзләр әйтеп күрмәгән.

Пакь җаның һәм пакь тәнең – барлык вөҗүдең пакь синең;
Син фәрештә валчыгысың, йөзләрең ап-ак синең!

Кыйл дога, ихлас белән тезлән дә кыйбла каршына;
Бел аны: керсез күңелдән тугъры юл бар гаршенә!

Әй бәһале, әй кадерле, әй гөнаһсыз яшь бала!
Рәхмәте бик киң аның, һәрдәм таян син Аллага!













Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Ошбу рәсемнәрне кисеп алып, аларны әкиятнең эчтәлегенә туры килерлек итеп икенче биттәге шакмаклар өстенә куй (ябыштырсаң, тагын да әйбәтрәк булыр).

Бүре

Этләр семьялыгындагы иң зур ерткыч – бүре. Моннан дүрт миллион ел элек үк йорт этләре белән бүреләр ике төркемгә аерылган дип фаразлыйлар.

Бүре Татарстанның һәрбер районында диярлек бар. Алар урманнарда яши.


Зур соры бүренең авырлыгы 34тән алып 56 килограммга чаклы җитәргә мөмкин. Ата бүре ана бүрегә караганда шактый зуррак була.

Бүренең йоны бик озын, калын. Ул 5-6 сантиметрга чаклы җитә.

Бүренең гәүдә озынлыгы 2 метрдан артып китәргә мөмкин.

Елга бер тапкыр бүре үзенең тунын (йонын) алыштыра. Кыш көне йоны озынрак, калынрак була.

Бүренең койрыгы да озын. Йоклаган чагында ул койрыгы белән аякларын, борынын каплый. Әкияттә надан итеп сурәтләнсә дә, тормышта бүре бик акыллы һәм зирәк җәнлек.





Карл Вениг. **«Казанны яулап алу»** картинасының төсле эскизыннан бер фрагмент. XIX гасыр. (Казан рәссамы В.Отмахов күчермәсе).

Хәтәр китә –
хәтер кала



Казанның канлы көзе

Эстониянең борынгы Ревель (Таллин) каласында туып, Россиянең Санкт-Петербург шәһәрендә яшәп иҗат иткән немец рәссамы Карл Венигның (1830-1903) «Казанны яулап алу» картинасы турында безгә нибары унбиш еллап элек кенә мәгълүм булды. Урыс дәүләтенең күршеләре җирләрен басып алуга юнәлтелгән империячел сәясәтен төсле буяулы сәнгати чаралар аша гаять оста һәм кискен фаш иткән бу картина, әлбәттә, зур-зур күргәзмәләргә куелмаган. Үз заманында киң танылган рәссамның исем-фамилиясен хәтта күп томлы «Зур совет энциклопедиясе»нә кертүне дә кирәк санамаганнар.

Ләкин көчле сәнгать чараларына төреп әйтелгән чын дөреслекне һичничек тыеп калып булмый. Узган гасырның текә үзгәреш җилләре исә башлаган туксанынчы елларында К.Вениг картинасы да башта 1903 елны «Родина» журналында басылган фотокүчермәсе аша (төп нөсхәсе әлегәчә табылмаган!), бераз соңрак Санкт-Петербургтагы Рус музеенда озак вакытлар «яшеренеп» яткан төсле эскизы аша халыкка кире әйләнеп кайтты. Казан каласының 1000 еллыгын каршы алган көннәрдә шушы эскиздан рәссам В.Отмахов ясаган төсле күчермә башкаланың милли–мәдәни үзәгендәге күргәзмәләр залына куелды.

Равил ВӘЛИ.

Хәйләкәр малай

Бер бала, уйный торгач, тәлинкәне ваткан да җәһәт кенә почмакка барып баскан.


– Әни, мин почмакка бастым, ә син тәлинкә ватыкларын җыеп ал инде!

Хитрый мальчик

Один мальчик, играя, разбил тарелку и поспешил встать в угол:

– Мама, я встал в угол, а ты, пожалуйста, собери осколки!





Табышмаклар


Үлән ашый, сөт ташый. (Сыер)
Туганда ук сакаллы. (Кәҗә)
Су түгел – сыек,
Кар түгел – ак. (Сөт)


Загадки


Сено жует, молоко дает. (Корова)
Рождается с бородой. (Коза)
Жидкое, но не вода,
Белое, но не снег. (Молоко)


Маэмай


















Пескәй














Кызыклы оригами

Төсле кәгазь алып, аны рәссам ясаган сызым ярдәмендә бөкләгез. Маэмай белән Пескәйне күп итеп ясагыз, үзара төрле уеннар уйный аласыз.



КАДЕРЛЕ ДУСЛАР!

Сезне кәгазьдән кошлар, җәнлекләр, чәчәкләр, көймә-кораблар... ясарга өйрәтик әле. Бүген Маэмайлы һәм Пескәйле (исемнәрен үзегез кушарсыз инде) **итәргә булдык үзегезне** (кәгазь ярдәмендә бөкләп әйберләр ясау Японияда оригами дип йөртелә).

Сәхифәнең рәссамы Диләрә НӘҮРУЗОВА